# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге составына керүче Яңа Мәлкән торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**20 ноябрь 2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» № 45-ТРЗ, 2023 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Яңа Мәлкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1-2 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан,мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

1)Яңа Мәлкән торак пунктында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Яңа Мәлкән торак пунктындагы зират территориясендә койма тоту (төзелеш материаллары алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Яңа Мәлкән торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә кертелде 332җыенда катнашучылар, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 169 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде 169халык җыенында катнашучылар;
"КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Сораулар буенча карар кабул ителде дип танырга:

«Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Яңа Мәлкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1-2 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан,мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

1)Яңа Мәлкән торак пунктында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Яңа Мәлкән торак пунктындагы зират территориясен коймалауны ремонтлау (төзелеш материаллары алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Яңа Мәлкән торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)-кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menzelinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ________________ З. И. Нәҗметдинов
(имза)

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ________________ З. И. Нәҗметдинов
(имза)